КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 декабрь г.Казань № 1278

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2021 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә;

4.6 пунктның 2 пунктчасындагы җиденче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге граждан-нарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турындагы нигезләмә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Респуб-ликасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карары белән расланган 2021 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турындагы нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның җиденче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инва-

лидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турындагы нигезләмә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карары белән расланган 2021 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турындагы нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2021 – 2022 елларда «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

2.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү сроклары, оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләрнең заявкаларын кабул итә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

3.1 пунктның икенче абзацында татар текстында «нәтиҗәләренә ирешү турында хисап» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның икенче абзацында татар текстында «нәтиҗәләренә ирешү турында хисап» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерү үткәрә.»;

5.2 пунктның беренче абзацында «финанс контроле органы» сүзләрен «дәүләт финанс контроле органы» сүзләренә алмаштырырга;

5.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин